**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

___________　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ __________

**«Мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирүне гамәлгә ашыручы Актаныш муниципаль районы белем бирү оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын карау, тәрбияләү һәм туклану өчен түләүдән азат итү турында» Башкарма комитет җитәкчесенең 2022 елның 10 октябрендәге ПР-207 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарын үтәү йөзеннән

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирүне гамәлгә ашыручы Актаныш муниципаль районы белем бирү оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын карау, тәрбияләү һәм туклану өчен түләүдән азат итү турында» Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 10 октябрендәге ПР-207 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

- мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмасына чираттан тыш кабул итү хокукын бирү;
- муниципаль белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучыларына ике тапкыр бушлай кайнар ризык (иртәнге аш, төшке аш) белән тәэмин итү;
- гомуми белем бирү оешмаларында озайтылган көн төркеменә йөрүче балаларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итү;
- өстәмә белем бирү учреждениеләрендә түгәрәкләргә һәм секцияләргә, гомуми белем бирү оешмалары базасында эшләүче өстәмә белем бирү түгәрәкләренә һәм секцияләренә бушлай йөрү.

2. Югарыда күрсәтелгән ташламалар, туендыручысын югалткан очракта, мобилизацияләнүче гаиләсендә яшәүче башка никахтан туган балаларга да кагыла.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы гражданның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт узу вакытына 2022 елның 14 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.М. Шакировага йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А.Ильясов